| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.07.2021 г.Казань № 491

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 5 августында 7835 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2021 елда вакытлыча эшкә урнаштыру чорында балигъ булмаганнарга һәм эшсез гражданнарга матди ярдәм күрсәтү күләмнәре турында» 2021 елның 8 февралендәге 58 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2021 елда вакытлыча эшкә урнаштыру чорында балигъ булмаганнарга һәм эшсез гражданнарга матди ярдәм күрсәтү күләмнәре турында» 2021 елның 8 февралендәге 58 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм белем яки квалификация турында документ тапшырылган датадан башлап ел дәвамында эш эзләгән 18 яшьтән 25 яшькәчә булган эшсез гражданнар өчен – аларны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына бер кешегә 4500 сум күләмендә;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорында бер кешегә 4500 сум күләмендә.».

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Министр вазыйфаларын башкаручы Р.Ф. Вәлиуллов